ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 март 2021ел № 1870

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 31 июлендәге 4534 номерлы;

2) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 31 декабрендәге 7629 номерлы;

3) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 28 июнендәге 3311 номерлы;

4) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5325 номерлы;

5) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 12 июлендәге 3906 номерлы;

6) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 июнендәге 3256 номерлы;

7) «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 23 августындагы 4359 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 18 мартындагы
1870 номерлы карарына
кушымта

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә,
реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – регламент) капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – АШТһТҮИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

АШТһТҮИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 248А кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр;

төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр;

ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

АШТһТҮИның белешмә телефоннары: 30-55-08, 30-58-12, 30-58-14.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: https://nabchelny.ru.

АШТһТҮИнең электрон почта адресы: gradoctroitel@mail.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatar.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://gosuslugi.ru);

5) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән;

6) Башкарма комитетта (АШТһТҮИ):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта аша электрон формада.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), ст. 16);

2) Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, ст. 4147);

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

5) «Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 169-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.11.1995, № 47, ст. 4473);

6) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, ст. 4563);

7) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү өчен кирәкле белдерү кәгазьләренең формаларын раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы (алга таба – РФ Төзелеш министрлыгы боерыгы) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://pravo.gov.ru, 28.09.2018);

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә рөхсәт бирү һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 729 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.10.2017, №728, № 4162 ст.);

9) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, №235-237, 10.12.2005; №249-250, 30.12.2005);

10) Шәһәр Советының 2007 елның 25 октябрендәге 26/4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре;

11) Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);

12) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

13) Башкарма комитетның 2012 елның 24 маендагы 372 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе турында нигезләмә (алга таба – АШТһТҮИ турында нигезләмә);

14) Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (1 нче кушымта);

2) техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу

мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

3) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны (алга таба – КФҮнең ерактагы эш урыны) – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Яр Чаллы шәһәрендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең (алга таба – КФҮ) территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы;<br>Муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Башкарма комитет исеменнән АШТһТҮИ | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы;<br>Шәһәр уставының 41 статьясы;<br>АШТһТҮИ турында нигезләмә |
| 2.3. Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган структур бүлекчәләре исемлеге | 1) АШТһТҮИ;<br>2) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) | Эш регламентының 3 бүлеге |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясы |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | 1) гариза теркәлгән көнннән башлап биш эш көне эчендә;<br>2) гариза теркәлгән көнннән башлап 30 көн эчендә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 11.1 бүлектә күрсәтелгән очракта);<br>3) җир участокларына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы гариза бирүчегә күчү, җир участогы барлыкка килү турында белдерү кәгазе алынган көннән башлап биш эш көне эчендә. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 11, 11.1 өлешләр |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү максатларында:<br>1) Гариза (1 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);<br>4) җир участогына хокук билгели торган документлар (әгәр күрсәтелгән документлар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булмаса);<br>5) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм расланган проект документларындагы түбәндәге материаллар (күрсәтелгән документлар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында яки Бердәм дәүләт бәяләмәләр реестрында булмаса):<br>- аңлатма язуы;<br>- җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, ә проект документларын линия объектларына карата әзерләгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган күчерү полосасы проекты (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);<br>- архитектура һәм конструктив чишелешләрне, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чишелешләр һәм чараларны үз эченә алган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт объектларына һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документлары әзерләгән очракта); | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7, 10.1 өлешләр;<br><br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлеш;<br>Министрлар Кабинетының 729 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | - капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын да кертеп);<br>6) аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү гамәлгә ашырыла торган проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе (мондый проект документлары РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5 статьясындагы 5 өлешкнең 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү өлешендә), шул исәптән әгәр әлеге проект документларында линия объектларын да кертеп, башка капиталь төзелеш объектлары төзү яки реконструкцияләү каралган очракта (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата), әгәр мондый проект документларына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза уздырылырга тиеш булса; РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документларына уңай дәүләт экспертиза бәяләмәсе; РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына уңай дәүләт экологик экспертиза бәяләмәсе (күрсәтелгән документлар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында яисә Бердәм дәүләт бәяләмәләр реестрында булмаган очракта);<br>7) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән һәм әлеге зат тарафыннан РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча җәлеп ителгән белгеч тарафыннан расланган проект | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;<br>8) башкарма хакимият органы яки проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә эксперт барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;<br>9) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, әлеге пунктның 12 пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш;<br>10) реконструкцияләү дәүләт хакимият органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы булып исәпләнгән дәүләт (муниципаль) заказчысы тарафыннан хокук иясе дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе булган, аңа карата күрсәтелгән орган гамәлгә куючы яки милек хуҗасы хокуклары функцияләре һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт (муниципаль) бюджет яки автономияле учреждениесенең дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектында үткәрелгән очракта - мондый реконструкцияләүне үткәрү турында реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | объектка салынган зыянны каплауның шартлары һәм тәртибен билгели торган килешү;<br>11) күпфатирлы йорт реконструкцияләнгән очракта күпфатирлы йортта биналар һәм машина-урыннары милекчеләренең торак законнары нигезендә кабул ителгән гомуми җыелышы карары яки, әгәр мондый реконструкцияләү нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме кимесә, күпфатирлы йорттагы барлык биналар һәм машина-урыннары милекчеләренең ризалыгы;<br>12) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсен биргән юридик затны аккредитацияләү турындагы таныклык күчермәсе, әгәр дә проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе бирелгән булса;<br>13) әгәр мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына кагылса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар.<br>Әгәр капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса, төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризага мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы бәяләмәсе, архитектура чишелешләрен үз эченә алган капиталь төзелеш объектының проект документлары бүлегенең тарихи җирлекне саклау предметына һәм федераль яки региональ әһәмияткә ия территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләренә туры килүе турында бәяләмә кушып бирелергә мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә капиталь төзелеш объектын төзегән яки реконструкцияләгән очракта, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, әлеге тарихи җирлек өчен расланган капиталь төзелеш объектының типовой архитектура чишелеше нигезендә, төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризада шундый типовой архитектура чишелеше күрсәтелә. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 21.14 статьясы |
| | Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертелгән очракта (шул исәптән төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайту зарурлыгына бәйле):<br>1) гариза (2 нче кушымта);<br>2) капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү өчен әлеге пунктта күрсәтелгән документлар;<br>Гариза бирүчегә җир участокларына, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкән очракта, җир участогын төзү турында гариза бирүче тарафыннан түбәндәге реквизитларны күрсәтеп белдерү кәгазе бирелә (3 нче кушымта):<br>1) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.5 өлешендә күрсәтелгән очракта, мондый җир участокларына хокук билгели торган документлар;<br>2) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә күрсәтелгән очракларда җир участоклары барлыкка килү турында карарлар, әгәр җир законнары нигезендә җир участокларын төзү турында карарны дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле үзидарә органы кабул итсә;<br>3) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.7 өлешендә күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.10 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | объектын төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган җир участогының шәһәр төзелеше планы;<br>4) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.9 өлешендә күрсәтелгән очракта җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында карарлар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар.<br>Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында җир участогына хокук билгели торган документлар турында мәгълүматлар булмаса, мондый документларның күчермәсен РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.5 өлешендә күрсәтелгән зат тапшырырга тиеш. | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.13 өлеше |
| | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән документлар бары тик электрон формада гына җибәрелә:<br>1) әгәр капиталь төзелеш объектының проект документларына уңай экспертиза бәяләмәсе (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата), РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе электрон формада тапшырылган булса;<br>2) әгәр мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган, капиталь төзелеш объектының проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәсе, шулай ук проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кирәкле башка документлар электрон формада тапшырылган булса. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булу сәбәпле, гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү максатында:<br>1) җир участогына хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, гавами сервитут билгеләү турында карар, шулай ук аның нигезендә күрсәтелгән җир участогы барлыкка килгән һәм җир участогының шәһәр төзелеше планы бирелгән территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7.3 өлешендә башкача билгеләнмәгән булса, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракта;<br>2) Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшыру турында килешү булганда – әлеге килешү, аның белән әлеге килешү төзелгән хокук иясенең җир участогына хокук билгели торган документлары;<br>3) җир участогының төзелеш өчен рөхсәт язуы алуга гариза бирелгән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән шәһәр төзелеше планы, яки линия объекты төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), аны урнаштыру өчен җир участогы булдыру таләп ителми торган линия объекты төзүгә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | рөхсәт биргән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары;<br>4) рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт (әгәр гариза бирүчегә мондый рөхсәт РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы нигезендә бирелгән булса);<br>5) капиталь төзелеш объектын төзегәндә территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яисә үзгәртү турында карар күчермәсе, аны урнаштырганда Россия Федерациясе законнары нигезендә территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиеш очракта, яки аның нәтиҗәсендә территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона яисә элек билгеләнгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона үзгәрергә тиеш капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта (01.01.2022 елдан кулланыла);<br>6) капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта территорияне үстерү турында шартнамә күчермәсе (территорияне комплекслы үстерү турында карар Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль тормышка ашырылган яки яисә мондый карар РФ Шәһәр төзелеше нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан тормышка ашырылган очраклардан тыш). | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан бирелү;<br>3) документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр булу;<br>4) документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар булмау;<br>2) тапшырылган документлар төзелешкә рөхсәт алу өчен җир участогының шәһәр төзелеше планы тапшырылган датага билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү таләпләренә туры килмәү;<br>3) тапшырылган документлар территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә туры килмәү (линия объекты төзүгә рөхсәт бирелгән очракта), линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш;<br>4) тапшырылган документлар җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәү;<br>5) тапшырылган документлар рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 13 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;<br>6) капиталь төзелеш объекты проект документларының бүлеге тарихи җирлекне саклау предметына һәм федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата капиталь төзелеш объектларының шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән архитектура чишелешләренә туры килмәү турында мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан кергән бәяләмә;<br>7) территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә нигезендә расланган территорияне планлаштыру буенча документлар булмау, әгәр капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү җирле үзидарә органы тарафыннан җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияләрне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә планлаштырылса (территорияне комплекслы үстерү турында карар Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль тормышка ашырылган яки яисә мондый карар РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан тормышка ашырылган очраклардан тыш).<br>Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир участогына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү, җир участогы барлыкка килү турында белдерү кәгазендә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 21.10 өлешендәге 1-4 пунктлар нигезендә каралган документларның реквизитлары | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.15 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | булмау яки РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта җир участогына хокук билгели торган документ булмау яисә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешендә каралган документлар булмау, мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтуга бәйле рәвештә генә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш;<br>2) җир участогына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү, җир участогы барлыкка килү турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән мәгълүматлар дөрес булмау;<br>3) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыру барлыкка килгән җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә туры килмәү. Шул ук вакытта җир участогының шәһәр төзелеше планы Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.10 өлешендә күрсәтелгән белдерү кәгазе җибәрелгән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелергә тиеш түгел;<br>4) төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта (мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш), планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыру төзелеш өчен рөхсәт алу өчен яки төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен тапшырылган җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә туры килмәү. Төзелешкә рөхсәт алынганнан соң бирелгән җир | |

| | | |
|---|---|---|
| | участогының шәһәр төзелеше планы төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен бирелгән очракта, мондый шәһәр төзелеше планы төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза җибәргән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелергә тиеш түгел;<br>5) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, төзүчедән төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта (мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш), планлаштырылган капиталь төзелеш объекты җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы карар кабул ителгән датага гамәлдә булган чикләүләргә туры килмәү;<br>6) төзүчедән төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта (мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш), планлаштырылган капиталь төзелеш объектын урнаштыру капиталь төзелеш объектын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылу өчен рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;<br>7) төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү төзелеш өчен рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле булган очракта, мондый хәбәр җибәрү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 5 өлеше таләпләре нигезендә мәҗбүри булып торса, мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гариза яки әлеге эшләрне башлау турында хәбәр булмау хакында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматы бирелгән көнгә, төзелеш өчен рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы, «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе яки «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге яки муниципаль җир контроле кысаларында ачыкланган төзелеш, реконструкцияләү буенча башланган эшләр булмау факты турында мәгълүмат булу;<br>8) төзелеш өчен рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы кимендә 10 эш көне эчендә төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза бирү. | |
| 2.10. Федераль, алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу – 15 минуттан артык түгел. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән көннән башлап бер көн эчендә | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрослар тутыру урыннарына, һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм исемлеге булган мәгълүмат стендларына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешнең 12 пункты<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>1) Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле санда белгечләр, шулай ук документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) инвалидларга башка затлар белән беррәттән муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр. | |
| 2.15. Башка, шул исәптән муниципаль хезмәтне КФҮдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы таләпләр | 1) Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлек итүе күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә. Муниципаль хезмәт КФҮдә, КФҮнең ерак эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешнең 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра;<br>2) Законда нигезендә муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү турында запрос бирү каралган очракта, мондый запрос Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша бирелә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.<br>Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүгә күчү муниципаль хокукый актлар белән расланган план-график нигезендә гамәлгә ашырылачак. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны КФҮләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү.

5) муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Гариза бирүче консультация алу өчен АШТһТҮИгә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша яисә электрон формада Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

АШТһТҮИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның (аларның күчермәләренең) составы, формасы, эчтәлеге буенча, кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның (аларның күчермәләренең) составы, формасы, эчтәлеге буенча консультацияләр.

3.2.2. Муниципаль хезмәтне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне ТР муниципаль берәмлекләренең интернет-кабул итү порталы (https://msu.tatarstan.ru) аша яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша алырга мөмкин.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче яки ул вәкаләтләгән зат эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша гариза бирә һәм регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра. КФҮнең ерактагы эш урыннары исемлеге регламентка 5 нче кушымтада бирелгән.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең яки аның вәкиленең шәхесен ачыклауны;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

3) регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерү;

4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасыннан файдаланып, гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

2) керә торган документларның теркәү карточкасын төзүне;

3) гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы турында штамп белән гаризаның күчермәсен (булганда) тапшыруны;

4) гаризаны һәм теркәлгән документларны карап тикшерү өчен, бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Регламентның 2.8 пункты нигезендә, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) гариза һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары гаризаны, документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. АШТһТҮИ башлыгы гаризны, документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен АШТһТҮИнең шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге башлыгына (алга таба - АШТһТҮИ бүлеге башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. АШТһТҮИ бүлеге башлыгы гариза, документларны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

### 3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. АШТһТҮИ бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соралган мәгълүматларны бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе (алга таба – мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе) җибәрә.

Җавап әзерләү һәм җибәрү срогы федераль закон белән билгеләнә.

Процедураның нәтиҗәсе: АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән мәгълүматлар яисә мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү

3.5.1. АШТһТҮИ бүлеге белгече алынган мәгълүматлар нигезендә:

1) төзелешкә рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документларның булуын тикшерә;

2) проект документларының төзелешкә рөхсәт алу өчен бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә, яки линия объекты төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), аны урнаштыру өчен җир участогы булдыру таләп ителми торган линия объекты төзелешенә рөхсәт биргән очракта, территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә туры килүен, шулай ук капиталь төзелеш объектының урнашуы җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр нигезендә урнашуын рөхсәт ителүен тикшерә. Затка рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирелгән очракта, проект документларының рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү үткәрелә;

3) капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт проектын (алга таба - рөхсәт проекты) яисә регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат (алга таба – баш тарту турында хат) проектын әзерли;

4) рөхсәт проектын яисә баш тарту турында хат проектын килештерү өчен АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен АШТһТҮИ бүлеге башлыгына җибәрелгән рөхсәт проекты яисә баш тарту турында хат.

3.5.2. АШТһТҮИ бүлеге башлыгы рөхсәт проектын яисә баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен АШТһТҮИ башлыгына җибәрелгән рөхсәт проекты яисә баш тарту турында хат.

3.5.3. АШТһТҮИ башлыгы рөхсәт проектын карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә яисә баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән рөхсәт проекты яисә имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.5.4 Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары рөхсәт проектын карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яисә баш тарту турында хатны карап тикшерә, имзалый һәм аны теркәү һәм гариза бирүчегә тапшыру өчен АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән рөхсәт проекты яисә АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.5.5. Башкарма комитет Җитәкчесе рөхсәт проектын имзалый һәм аны теркәү өчен

эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән рөхсәт проекты.

3.5.6. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) рөхсәт проектын терки, Башкарма комитет мөһере белән раслый;

2) рөхсәтне АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, АШТһТҮИ бүлеге белгеченә җибәрелгән рөхсәт.

3.5.7. АШТһТҮИ бүлеге белгече:

1) баш тарту турында хат проектын теркәү журналында терки;

2) гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә;

3) гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирә яисә почта аша җибәрә;

4) рөхсәт күчермәсен җибәрә:

- дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясының 5.1 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта яки дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма хакимият органына, капиталь төзелешнең башка объектларын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта;

- реконструкцияләү максатларында рөхсәт бирелгән объектны урнаштыру сәбәпле, территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар кабул иткән дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 өлешендәге 9 пунктында каралган очракларда).

Әлеге пунктның 1, 2 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктның 3 пунктчасында билгеләнә торган процедура әлеге пунктның 2 пунктчасында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктның 4 пунктчасында билгеләнә торган процедура төзелешкә рөхсәт бирелгән көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яисә почта аша җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе, дәүләт хакимияте органнарына җибәрелгән рөхсәт күчермәсе.

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза, аларга җир участокларына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү, җир участогы барлыкка килү турында белдерү кәгазе кергәндә, регламентның 3.3-3.5 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

3.6. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә яисә КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (регламентка 2 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

3) юридик көчкә ия һәм техник хата булуны таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), яисә Татарстан республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече теркәлгән документлары белән техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны терки һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.7.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында регламентның 3.3.3-3.3.5 һәм 3.5 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

АШТһТҮИ бүлеге белгече техник хата булган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алгач, шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки почта аша (электрон почта аша) гариза бирүченең адресына, техник хата булган документның төп нөсхәсен АШТһТҮИгә тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турындагы хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Регламент үтәлеше тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруга билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә

муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләре турында рәсми язулар бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәү өчен җаваплы.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары һәм АШТһТҮИ башлыгы регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен Башкарма комитетның вазыйфаи затлары һәм башка муниципаль хезмәткәрләре законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.5 Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан регламент үтәлешен контрольдә тоту, муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең эш итүләренә (эш итмәүләренә) Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне гамәлгә куючы гавами - хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, шулай ук КФҮнең һәм КФҮ хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән

документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, Интернет челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтүче органның (Башкарма комитет), Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре бирелергә мөмкин.

5.5. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) гариза бирүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
_________________________________
(Ф.И.А.и.)
_________________________________
_________________________________
_________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм
(булганда) атасының исеме, гариза
бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең
шәхесен раслаучы документ
реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме
һәм урнашу урыны,
бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик
затның дәүләт теркәве турында язманың
дәүләт теркәү номеры,
салым түләүченең идентификация
номеры (гариза бирүче чит ил юридик
заты булган очраклардан тыш)
_________________________________
_________________________________
(почта адресы һәм (яки)
электрон почта адресы)

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында гариза

Сездән _______________________________________________________________
(шәһәр, район, урам, участокның номеры)
буенча урнашкан ___________________________кадастр номерлы җир участогында
____________________________________________________________
(барлык төзелеш-монтаж эшләрен, аерым эш төрләрен,
_______________________________________________________________
әзерлек эшләрен алып баруга рөхсәт – кирәклесен сызарга, объектның исеме)
_______________________________________________________________
________________________срокка рөхсәт бирүегезне сорыйм.
Шул ук вакытта хәбәр итәм:
1) Җир участогына хокук билгеләүче (хокук раслаучы) документ ______________________________
«__» _________ 20__ ел № _____________;
2) объектны төзүгә проект документлары ______________________________
_______________________________________________________________
(проект оешмасының исеме,
_______________________________________________________________
лицензия биргән лицензион үзәкнең исеме)
20__ елның «__» _________ _____________номеры белән эшләнгән һәм тиешле тәртиптә архитектура һәм шәһәр төзелеше оешмалары һәм органнары белән килештерелгән;
3) дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе 20__ елның «__»_________ _________ номеры белән алынган;
4) җир участогының генераль планы _______________________________________________
(җир участогының генераль планын биргән органның исеме)
20__ елның «__» _________ _____________номеры белән әзерләнгән;
5) проект ___________________________________________________
(оешманың исеме)
тарафыннан 20__ елның «__» _________ _____________номерлы приказ белән расланган.

Бер үк вакытта Сезгә түбәндәгеләр турында хәбәр итәм:
а) төзелешне финанслау заказчы (төзүче) тарафыннан башкарылачак

___________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)
б) эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән алып барылачак

___________________________________________________________________
(милек формасын һәм банк реквизитларын күрсәтеп оешманың исеме)
___________________________________________________________________
Төзелеш-монтаж эшләрен алып бару хокукына документлар
_______________________________________ 20__ елның «__» _______ _____________номеры белән бирелгән;
(оешманың исеме)
в) 20__ елның «__» _________ _________номерлы приказ белән
эшләрне башкаручы итеп ____________________________________билгеләнгән, __________________________
(вазыйфасы, Ф.И.А.и.) (югары, урта)
һөнәри белемле, төзелештәге эш стажы ___________ ел;
г) автор күзәтчелеге 20__ елның «__» ________ ____номерлы шартнамә нигезендә

___________________________________________________________________
банк реквизитлары белән оешманың исеме
___________________________________________________________________ башкарылачак,
(хезмәткәрнең вазыйфасы, Ф.И.А.и., телефон номеры)
20__ елның «__» ________ ____________ номерлы приказ белән билгеләнгән,
_____________________________ һөнәри белемле
(югары, урта)
һәм төзелеш һәм проектлаштыруда эш стажы __________ ел;
д) техник күзәтчелек 20__ елның «__» ________ ____номерлы шартнамә нигезендә

___________________________________________________________________
банк реквизитлары белән оешманың исеме
___________________________________________________________________ башкарылачак,
(хезмәткәрнең вазыйфасы, Ф.И.А.и., телефон номеры)
20__ елның «__» ________ ____________ номерлы приказ белән билгеләнгән,
_____________________________ һөнәри белемле
(югары, урта)
һәм төзелеш һәм проектлаштыруда эш стажы ____________ ел.
Объектның төп күрсәткечләре: ________________________________________
___________________________________________________________________

Әлеге гаризадагы мәгълүматлар белән бәйле барлык үзгәрешләр һәм мәҗбүри нормаларны һәм регламентларны бозулар турында Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә хәбәр итәргә йөкләмә алам.

Заказчы (төзүче)
_______________________ ______________ ___________________________
(гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) (имза) (Ф.И.А.и.)
М.У.

Документларны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече кабул итте

__________ __________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
______________________________________
(Ф.И.А.и.)
________________________________________
________________________________________
________________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм
(булганда) атасының исеме, гариза
бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең
шәхесен раслаучы документ
реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме
һәм урнашу урыны,
бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик
затның дәүләт теркәве турында язманың
дәүләт теркәү номеры,
салым түләүченең идентификация
номеры (гариза бирүче чит ил юридик
заты булган очраклардан тыш)
______________________________________
______________________________________
(почта адресы һәм (яки)
электрон почта адресы)

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә,
реконструкцияләүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында
гариза

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының исеме һәм адресы)
объекты буенча 20______елның «__» ________ __________номерлы капиталь төзелеш объектларын төзүгә,
реконструкцияләүгә рөхсәткә __________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
(үзгәрешләр кертүнең сәбәпләрен һәм документ реквизитларын күрсәтеп)
бәйле үзгәрешләр кертүне сорыйм.
Кушымта:
1. _________________________________________________________________________
2. _________________________________________________________________________
(гаризага теркәлә торган документларның исемлеге)

_____________________ _____________ ______________________________
(гариза бирүченең вазыйфасы - (имза) (Ф.И.А.и.)
юридик зат өчен)

«__» ___________ 20__ ел
М.У.

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
___________________________________
(Ф.И.А.и.)
____________________________________
____________________________________
____________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм (булганда) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны,
бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры,
салым түләүченең идентификация номеры (гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш)
___________________________________
___________________________________
(почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы)

Җир участогына (участокларына) хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук күчү, җир участогы барлыкка килү турында белдерү кәгазе

_______________________________________________________________
______________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының исеме һәм адресы)
объекты буенча 20______елның «__» ________ __________номерлы төзелешкә рөхсәткә ____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
(сәбәпләрне һәм Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 21.10 өлешнең 1,2, 3 пунктларында күрсәтелгән документ реквизитларын күрсәтеп)
бәйле үзгәрешләр кертүне сорыйм.
Кушымта:
1. ____________________________________________________________________
2. ____________________________________________________________________
(гаризага теркәлә торган документларның исемлеге)

______________________ ____________ ____________________________
(гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) (имза) (Ф.И.А.и.)

«__» __________ 20__ ел
М.У.

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына
4 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
_______________________________
(Ф.И.А.и.)
_______________________________
_______________________________
_______________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм
(булганда) атасының исеме, гариза
бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең
шәхесен раслаучы документ
реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме
һәм урнашу урыны,
бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик
затның дәүләт теркәве турында язманың
дәүләт теркәү номеры,
салым түләүченең идентификация
номеры (гариза бирүче чит ил юридик
заты булган очраклардан тыш)
_______________________________
_______________________________
(почта адресы һәм (яки)
электрон почта адресы)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
_______________________________________________________________
(муниципаль хезмәтнең исеме)
Язылган:_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ____________________________________________
_______________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.
Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:
электрон документны E-mail: ____________________ адресына җибәрү юлы белән
кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
_______________________________________________________________.
Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.
Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: ________________.

| ________________________ | _____________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (гариза бирүченең вазыйфасы - юридик зат өчен) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

«__» __________ 20__ ел.
М.У.

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына
5 нче кушымта

КФҮнең ерактагы эш урыннарының
исемлеге

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр
күрсәтү буенча КФҮ» ДБУ филиалы

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» МБУ, адресы: Кол Гали бульвары, 25 Е йорт (Яңа шәһәр 59/04);

2. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» ДБУ Яр Чаллы филиалының өстәмә офисы: Тынычлык проспекты, 62 йорт (Яңа шәһәр 3/16).

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына
кушымта (белешмә)

Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм
аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының
телефоннары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 30-55-08 | gradoctroitel@mail.ru |
| Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы | 30-55-08 | gradoctroitel@mail.ru |
| Шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәтләр бирү бүлеге башлыгы | 30-58-12 | gradoctroitel@mail.ru |
| Бүлек белгече | 30-58-12 | gradoctroitel@mail.ru |